КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 3 ноябрь г.Казань № 1415

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Марсель Сәлимҗанов исемендәге театр сәнгате өлкәсендә республика премиясе турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1087 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Марсель Сәлимҗанов исемендәге театр сәнгате өлкәсендә республика премиясе турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1087 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 17 июль, 572 нче; 2019 ел, 6 сентябрь, 796 нчы; 2022 ел, 2 сентябрь, 945 нче; 2023 ел, 23 май, 628 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Марсель Сәлимҗанов исемендәге театр сәнгате өлкәсендә республика премиясе турындагы нигезләмәдә:

5 пунктта «15 июленә» сүзләрен «7 ноябренә» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктның бишенче абзацында «Марсель Сәлимҗановның туган көнендә (һәр так елның 7 ноябрендә)» сүзләрен «әлеге Нигезләмәнең 5 пункты нигезендә кандидатларның эшләре һәм әсәрләре турында материаллар кабул итү тәмамланган көннән алып 30 календарь көн эчендә» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Марсель Сәлимҗанов исемендәге театр сәнгате өлкәсендә республика премиясен бирү буенча конкурс комиссиясе составында:

составтан Р.З.Закировны чыгарырга;

составка «Бөтендөнья татар конгрессы» төбәкара иҗтимагый оешмасының башкарма комитеты рәисе Данис Фәнис улы Шакировны (килешү буенча) кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин